| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» сентябрь, 2024 ел Олы Кайбыч ав. № 96

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 28 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6)

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык һәм алардагы бүлмәләрдә булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләренә (комплекслар) карата 1,2%.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Олы Кайбыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин